

Мордовия Республикасы Матбугат үзәгендә Яна ел бәйрәмнәре чоры, һичшиксез, оператив хезмәтләр очен әзерлекнен югары вакыты, әмма бу коннәрдәге куркынычлар шул ук: куркыныч метеорологик күренешләр, юл-транспорт һәлакәтләре, коммуналь аварияләр һәм, әлбәттә, янгыннар. Мәтбугат вәкилләре белән Яна ел бәйрәмнәре һәм мәктәп каникуллары вакытында янгын куркынычсызлыгын профилактикалау темасына чарада катнашучылар сойләде. Катнашучылар:

Сергей Викторович Репин, Мордовия Республикасы буенча Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарә житәкчесе (начальник Главного управления МЧС России по Республике Мордовия);

Александр Александрович Болталин, Баш идарә житәкчесе урынбасары, күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе житәкчесе (Заместитель начальника Главного управления - начальник управления надзорной деятельности и профилактической работы);

Андрей Геннадьевич Наумов, Мордовия Республикасынын Граждannар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча Дәүләт комитеты рәисе (Председатель Государственного комитета по делам гражданской обороны и чрезвычайным ситуациям Республики Мордовия);

Александр Юрьевич Афтайкин, РМ буенча Эчке эшләр министрлыгынын җәмәгать тәртибен саклауны оештыру идарә бүлеге житәкчесе урынбасары (заместитель начальника отдела организации охраны общественного порядка Управления МВД по РМ);

Алексей Васильевич Матюшин, Саранск шәһәре хужалыгы мәсьәләләре идарәсе житәкчесенен беренче урынбасары (первый заместитель начальника управления по вопросам городского хозяйства г.о. Саранск);

Татьяна Юрьевна Салищева, Саранск шәһәре хакимиятенен мәдәният идарәсе житәкчесе (начальник управления культуры администрации г.о. Саранск).

Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын Мордовия Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы Сергей Репин янгыннар белән бәйле актуаль хәл турында сойләде, салкыннар башлану белән электр жиһазлары тозек булмау яки мич белән жылыту сәбәпле янгын чыгу куркынычы шактый арта. Ә Яна ел бәйрәмнәрендә янгыннар һәм кешеләрнен үлеме саны, кагыйдә буларак, арта. Шуна бәйле рәвештә, баш идарә янгын куркынычсызлыгы буенча профилактик чаралар комплексын кочәйтте.

Баш идарә начальнигы урынбасары күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе начальнигы Александр Болталин Яна елны бәйрәм итү белән бәйле моһим проблемага - пиротехника продукциясен кулланганда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуга кагылды. Ул катнашучыларга пиротехника куллануга таләпләрне искә тошерде һәм барысын да Яна ел белән котлады.

“Иминлек безнен һәрберебездән башлана”, - дип билгеләп үтте Мордовия Республикасынын Граждannар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча дәүләт комитеты рәисе Андрей Наумов. Чонки статистика буенча күпчелек очракта янгын сәбәпләре – “кеше факторы”. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәргә кирәк. Андрей Геннадьевич граждannарга янгын вакытында куркынычларны киметүнен топ

мобиль чараларын санга сугарга, янгын сvндерvче (огнетушитель) сатып алырга һәм йортларга янгын хәбәрчеләре урнаштырырга киңәш итә.
Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре булачак массакvләм чараларны vткәргәндә җәмәгать тәртибен саклау оештырылуы турында хәбәр итте.
Ә шәһәр хуҗалыгы департаменты вәкилләре Яна ел программасы планын һәм бәйрәм мәйданчыклары исемлеген игълан итте.

**Наилә НАСЫРОВА**